## Үз-үзен үтерәчәк террорчыны фаш итәргә мөмкин билгеләр

### Яше

Үз-үзен үтерүче террорчылар, кагыйдә буларак, 20–24 яшьләрдәге затлар, күбрәк хатын-кызлар

### Гадәти булмаган кием

Сезон буенча киенмәгән. Шартлаткыч җайланманы яшерү өчен киң күлмәк яисә киң пәлтә кигән. Куллары кесәдә яки кием бөрмәләрендә, хәрәкәтләнгәндә кием астына яшерелгән предмет беленеп китәргә мөмкин.

### Тышкы билгеләре

Сак кына күчерелә торган йөк. Шартлаткыч җайланма рюкзакка, хуҗалык сумкасына һәм пакетка салынырга мөмкин. Пакетта булса, гадәттә аны кочаклап бара.
Ир-атлар чиста итеп кырынган, бу үз-үзен үтерер алдыннан башкарыла торган чистарынуның бер өлешен аңлата.

### Үз-үзен тотышы

Тынычсыз, кулындагы сумкасын, рюкзагын кочаклап тоткан, як-якка карана, шартлаткыч гәүдәгә беркетелгән очракта, хәрәкәте гадәти түгел.
Тагын бер билгесе – кеше апатиягә бирелгән, салкын карашлы, наркотик яисә психотроп йогынты билгеләре күренеп тора.
Үз-үзен үтерүчеләр еш кына кычкырып, кеше якынлаша башласа пышылдауга күчеп дога укый.
Мондый затларның барысы да кеше аеруча күп җыелган җиргә барырга тырыша.

### Эстремаль хәлдә нишләргә?

Террорчылык актын алдан белеп булмый, шуңа күрә бу хәлгә һәрвакыт әзер булырга кирәк. Террорчылар һөҗүм ясар өчен билгеле һәм кеше күп йөри торган урыннарны, мәсәлән, эре шәһәрләрне, халыкара аэропортларны, эре халыкара чаралар үткәрү урыннарын, халыкара ял йортларын һ.б сайлый. Һөҗүм ясау урынын сайлауның төп шарты – хокук саклау структуралары игътибарыннан, мәсәлән, терактка кадәр тикшерүләрдән качып калу мөмкинлеге.

**Мондый урыннарда булганда аеруча сак булыгыз!**

### Ваемсыз булмагыз!




02 номерына шалтыратыгыз йә полиция хезмәткәренә мөрәҗәгать итегез. Телефоннан мөмкин кадәр тыныч сөйләшергә, исем-фамилияне, кайда булуыңны һәм нинди предметка тап булганны хәбәр итәргә кирәк.

### Шикле әйбергә кагылмагыз!



Шикле әйбергә кайда тап булуыгызга карамастан, сезнең бурыч – табылдык хакында хәбәр итү! Мөстәкыйль гамәлләр кылырга тырышмагыз! Мондый очракта сез бары тик хәбәр итәргә һәм куркыныч янамый торган ераклыкка китеп басарга тиеш.

### Истә тотыгыз!

Сумка, әрҗә, пакетлар гына түгел, гадәти булмаган, башкаларына охшамаган предметлар да игътибарны җәлеп итәргә тиеш. Мәсәлән, шикле предметлары булган машина күргәнсез икән, шалтыратып, табылдык хакында хәбәр итегез.